**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 декабрендәге 5472 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 29 октябрендәге 3049 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 459 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга

үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 октябрендәге 3049 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендәраслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 459 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 декабрендәге
5472 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 29 октябрендәге 3049 номерлы карары белән расланган**
**«Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен**
**планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 октябрендәге 3049 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру проекты территориясен план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә 4 нче «Транспорт инфраструктурасы объектлары характеристикалары» пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«16:50:060632:1460 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан «Паруса» торак комплексы паркингында, планлаштыру проекты чикләреннән читтә, 16:50:060627:888 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан «Малевич» торак комплексын парковка урыннары белән тәэмин итү максатыннан, 120 машина урыны булдыру күздә тотыла».

___________________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 декабрендәге
5472 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 25 февралендәге 459 номерлы карары белән расланган
«Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру
һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 459 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проекты территориясен план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә 4 нче «Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикалары» пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«16:50:060627:888 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан «Малевич» торак комплексы өчен әлеге кишәрлек чикләрендә кимендә 300 машина урыны булдырыла. Машина урыннарын җир кишәрлеге өслегендә һәм җир асты парковкасында урнаштыру каралган. Җитмәгән 120 машина урынын планлаштыру проекты чикләреннән читтә, 16:50:060632:1460 кадастр номерлы җир кишәрлегендә, «Паруса» торак комплексының Гадел Кутуй урамы, 110Д йорт, 4 корпус адресы буенча урнашкан җир асты парковкасында булдыру күздә тотыла».

___________________________